Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАРЫ

25 июль 2022 ел № 11

Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 6 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Клементейкино авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 6 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

2.5. бүлеге 2.5.1 пунктындагы 5,6 пунктчаларын төшереп калдырырга;

1.2. 2.6. бүлеге 2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчаны өстәргә:

«4) индивидуаль торак йортка хокук билгеле торган документлар (әгәр милек хокукы Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса)".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Клементейкино авылы, Центральная урамы, 38А йорт; Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 38А йорт; Яңа Чишмә авылы, Гафиятуллин урамы, 3А йорт, территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Клементейкино авылы башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Э. Языков